БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__25__» ___05____ 2020 г. № __185___

**Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октяберендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсе, «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен түләүне кичектереп торуны бирү турында» 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба муниципаль мөлкәт) арендалау шартнамәләре буенча Балтач муниципаль районы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендага алучылар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгатеннән соң 7 эш көне дәвамында муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның апрель-июнь айларында аренда түләүләрен түләүне, кичектерелгән аренда түләүләрен түләү вакыты 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча башлану шарты белән, мондый арендага алучылар тарафыннан тәкъдим ителгән вакытка кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү;

б) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында арендага алучылар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге карар үз көченә кергән көннән өч эш көне эчендә әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Билгеләргә:

а) аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендага алучыларга - кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә;

б) әлеге карарның 1 пунктының «а» пунктчасы нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель - июнь айлары өчен аренда түләвен түләүне кичектереп торуны һәм аны 2020 һәм (яисә) 2021 елларда аренда шартнамәсендә каралган вакытка тигез өлешләр белән түләүне, шулай ук аренда шартнамәсен вакытыннан алда өзгәндә кичектерү бирелә торган аренда түләүләре суммасын бер тапкыр түләүне күздә тотарга тиеш.

3. Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына 2020 елның II кварталыннан башлап хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча әлеге карарның үтәлеше турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми http://www.baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга һәм түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://www.pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов